БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 25 » июль 2018 ел № 267

**Балтач муниципаль районы мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасының муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча административ регламентларын раслау турында**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге ФЗ-210 номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатыннан, «Татарстан Республикасының дәүләт хакимиятенең башкарма органнары дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең исемлеген раслаутурында» 2018 елның 5 июлендәге 242 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карары нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты **карар бирә**:

1. Расларга:

1.1. Муниципаль торак фондының торак урыннарын гражданнар милкенә тапшырганда документлар рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында (1 нче кушымта);

1.2. Мунинципаль учреждениеләргә һәм муниципаль казна предприятияләренә муниципаль мөлкәтне оператив идарә итү хокукы белән һәм муниципаль унитар предприятияләргә муниципаль мөлкәтне хуҗалык алып бару хокукы белән рәсмиләштерү (ныгыту) буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (2 нче кушымта);

1.3. Муниципаль мөлкәт (күчемсез мөлкәт объектларына муниципаль милек) реестрыннан өземтә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (3 нче кушымта);

1.4. Муниципаль преференцияләр бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (4 нче кушымта);

1.5. Муниципаль милектә булган һәм арендага бирү өчен каралган күчемсез милек объектлары турында мәгълүмат бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (5 нче кушымта);

1.6. Муниципаль казнага кергән милекне арендага тапшыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү административ регламенты (6 нчы кушымта);

1.7. Җир кишәрлеген арендалау шартнамәсенә үзгәрешләр кертү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү административ регламенты (7 нче кушымта);

1.8. Муниципаль милекне арендалау килешүенә, оператив идарә итү килешүенә, туләүсез файдалану, хуҗалык алып бару буенча өстәмә килешүне раслау турында муниципаль хезмәт күрсәтү административ регламенты (8 нче кушымта);

1.9. Элек хосусыйлаштырылган торак урыннарны муниципаль милеккә кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (9 нчы кушымта);

1.10. Муниципаль милек реестрына керүче муниципаль мөлкәтне арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (10 нчы кушымта);

1.11. Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына муниципаль мөлкәтне биләүгә һәм (яки) файдалануга тапшыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (11 нче кушымта);

1.12. Муниципаль берәмлекнең муниципаль мөлкәтен сатулар үткәрмичә түләүсез файдалануга тапшыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (12 нче кушымта);

1.13. Мондый шартнамәне төзү хокукына сату нәтиҗәләре буенча муниципаль мөлкәттән түләүсез файдалану шартнамәсе төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (13 нче кушымта);

1.14. Муниципаль мөлкәтнең гамәлдәге аренда шартнамәсен өзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (14 нче кушымта);

1.15. Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрне башка категориядәге җирләргә күчерүне килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (15 нче кушымта);

1.16. Хосусый яки муниципаль милеккә кергән җир кишәрлеген бер категориядәге җирләрдән (авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән тыш) икенче категориягә күчерү турында карар кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (16 нчы кушымта);

1.17. Җир кишәрлекләрен бушлай алу хокукына ия булган затларны исәпкә кую буенча (Татарстан Республикасынын Җир кодексынын 32 нче статьясы нигезендә) һәм җир кишәрлекләрен гражданнарга уртак милеккә бушлай бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү административ регламенты (17 нче кушымта);

1.18. Муниципаль милектә булган җир кишәрлеген сатулар үткәрмичә сату буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (18 нче кушымта);

1.19. Җир кишәрлегенең яки җир кишәрлекләренең территориянең кадастр планында урнашу схемасын рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (19 нчы кушымта);

1.20. Муниципаль милектәге җир кишәрлеген аукцион үткәрмичә арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (20 нче кушымта);

1.21. Җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (21 нче кушымта);

1.22. Муниципаль милектәге җир кишәрлекләрен гражданнарга һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларына крестьян (фермер) хуҗалыгының эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен милеккә (арендага) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (22 нче кушымта);

1.23. Муниципаль милектәге җир кишәрлеген җир кишәрлегендә урнашкан биналар, корылмалар милекчеләренә милеккә яки арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (23 нче кушымта);

1.24. Муниципаль милектәге җир кишәрлеген торак пункт чикләрендә шәхси хуҗалык алып бару өчен гражданнарга милеккә (арендага) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (24 нче кушымта);

1.25. Муниципаль милектәге җир кишәрлеген бакчачылык алып бару өчен гражданнарга милеккә (арендага) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (25 нче кушымта);

1.26. Муниципаль милектәге җир кишәрлеген бакчачылык - дача хужалыгы алып бару өчен гражданнарга милеккә (арендага) бирү буенча муниципаль хезмәт курсәтүнең административ регламенты (26 нчы кушымта);

1.27. Муниципаль милектәге җир кишәрлеген даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (27 нче кушымта);

1.28. Муниципаль милектәге жир кишәрлеген милеккә бушлай бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (28 нче кушымта);

1.29. Муниципаль милектәге жир кишәрлеген түләүсез вакытлы файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (29 нчы кушымта);

1.30. Муниципаль милектәге җир кишәрлеген аукцион формасында үткәрелә торган сатуларда арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (30 нчы кушымта);

1.31. Муниципаль милектәге җир кишәрлеген аукцион формасында үткәрелә торган сатуларда милеккә сату буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (31 нче кушымта);

1.32. Дәүләт яки муниципаль милектә булган һәм шәхси милектә булган җирләрне һәм (яисә) җир кишәрлекләрен кабат бүлү турында килешү төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (32 нче кушымта);

1.33. Муниципаль милкектә булган җирләрне яки җир кишәрлеген файдалануга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (33 нче кушымта);

1.34. Җир кишәрлегеннән даими (чикләнмәгән вакытка) файдалану хокукын яки җир кишәрлегенә гомерлек мирас итеп алу хокукын туктату

турында карар кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (34 нче кушымта);

1.35. Җир кишәрлеген сатып алу турында карар кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (35 нче кушымта);

1.36. Муниципаль милектәге җир кишәрлегенә сервитут билгеләү турында килешү төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (36 нчы кушымта);

1.37. Җир кишәрлегеннән файдалануның шартлыча рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (37 нче кушымта);

1.38. Муниципаль милектәге җир кишәрлеген шәхси торак төзелеше өчен гражданнарга милеккә (арендага) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (38 нче кушымта).

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы» интернет – ресурсында бастырырга һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач районы башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
житәкчесе Р.И.Шакиров